**Иң зур байлык - тәрбияле бала**

# Кыз баланы тәрбияләү көндез йолдызны күрүгә тиң

**“Кыз баланы тәрбияләү көндез йолдызны күрүгә тиң”, дигән фикер күңелдә уелып калган. Әгәр дә сез борынгы татар халык мәкальләренә игътибар итсәгез, гаҗәеп ачышлар ясарсыз. Һәр татар мәкале тирән фәлсәфи мәгънәгә ия. Бер җөмләле фикергә педагогик ысул салынган булыр.**

Коры сүз булып калмасын өчен, мисал да китереп узасым килә. “Кара ташны юып, көчеңне сарыф итмә”. “Иделгә таянма, иргә ышанма”. Мәкальләрнең әчтәлегенә төшенер өчен, әлбәттә, тормыш тәҗрибәсе булу мәҗбүри.

### Тәрбия эше - иң читен хезмәт

Тормышта, яшәештә иң авыр эш нәрсә дип сорасалар, мин үзем: «Тәрбия эше», - дияр идем. Ләкин дә, тәрбия белән шөгыльләнер өчен берничә шарт кирәк. Бу очракта мин үз баламны тәбияләүне күздә тотам. Үзеңдә Дәү әти һәм Дәү әни тәрбиясен күрү зарури. Кемдер Зур әти һәм Зур әни, дип әйтә. Бу сүзләрне әти кешенең ата-анасына әйтергә тиеш бала. Әнисенең әти-әнисенә әби-бабай әйтелә.

Икенчедән, әти-әни кулы аша узарга. Укырга, укырга, укырга!

Чөнки китапта - шул ук кеше язмышлары.

Ләкин дә барчасы да хезмәт белән уралып барырга тиеш.

Тормышта беркайчан да эш бетми. Аны күрә белергә генә кирәк. Бала ул сыйфатларга ия түгел, шуңа да аңа эшне кушарга дигән нәрсә бар.

Тәрбия өлкәсендә сансыз китаплар. Барчасын да укысаң, тәрбиячененң үзенең үк буталып калуы бар.

### Изге Китабыбыз Коръән-Кәрим - иң ышанычлы тәрбияче

Безгә, татарларга, Ходай Тәгалә гомерлек тәрбия китабын бүләк иткән - ул изге Китабыбыз Коръән-Кәриме һәм хәдисләр. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) әйткән: “Шигырьдә хикмәт бардыр”. ”Сак-сок” бәетен йокы алдыннан балага укыганда аның күзләрен күрергә кирәк!

Хәдисләребезнең берсендә: ”Өч кыз баланы дөрес юлда яшәрлек итеп тәрбияләгән атага оҗмах ишекләре ачылыр”, диелгән. Бу очракта тәрбия эшенең никадәр авыр икәнен күздә тотып әйтелгән низамнамә. Ир дә, хатын да бертигез, дип фикер йөртүчеләр ялгышалар. Алар тигез була алмыйлар, чөнки Ходай Тәгалә аларның икесенә ике төрле вазыйфа йөкләгән. Изге Китабыбыз буенча ир кеше, ата кеше бала өчен генә түгел, хатын өчен дә җаваплы.

### Кыз һәм малай аерым ысуллар таләп итә

Малай кешене тәрбияләү ысулы бер булса, кыз баланы тәрбияләү бөтенләй башкача. Үземнең яраткан әйберләрем күп. Шулар арасында чәчәкләр һәм гөлләр дә бар. Алар миңа кызым Наиләне тәрбияләргә үзенә бер чыганак булып та хезмәт иттеләр. Кыз баланы тәрбияләү гөл үстерүдәй четерекле, ләкин дә авыррак.

Тәрбия нидән башлана? - дигән сорауга җавабы да читен түгел. Үзеңнән. Үзеңдә булмаган сыйфатны балаңда булдыру - бик читен хезмәт. Ләкин дә тәрбия эшендә олыларның өстенлеге шунда ки, үзе белмәгәнне, җавапны таба белә һәм үзенең кимчелеген яшерергә теоретик нигезне китереп куя ала. Мәсәлән. “Балалар аталарны узарга тиеш. Шулай булмаса, тәрәккыят (прогресс) туктала”. Ышандырырлык дәлил!

### Кеше ничә мәртәбә ялгыша?

Һәр бала - ике кешенең йөрәк җимеше. Һәр бала - сәләт иясе. Аны күрә белергә генә кирәк. Яшьләр белән аралашырга яратам. Аларга стандарт сорауларым бар. Шуларның берсе: «Кеше үз гомерендә ничә мәртәбә ялгыша?” Моңа барчасы да: “Миллион”, - дип җавап бирә. «Юк, - дим - кеше үз гомерендә ике генә мәртәбә ялгыша - һөнәр сайлаганда һәм өйләнгәндә, кияүгә чыкканда». Ризалашалар. Кием алганда барчабыз да баланы кибеткә алып барып, кигезеп карыйбыз. Бала моны күреп үсә. Киемне баладан башка алсак, аны кабат барып алмаштырырга була. Ә бит кияүгә чыгу һәм өйләнү - кием алудан мең мәртәбә читенрәк эш! Шуны сеңдерергә кирәк балага.

### Мәхәббәтнең иң олысы милләтеңә багышлансын

Мәхәббәт. Изге тойгы. Ярату. Сафлык. Ләкин дә балага иң олуг хис - үз татарыңа булган мәхәббәтне, үзебезнең асыл һәм иң пакь динебез Исламга булган мәхәббәтне беренче булып сеңдерергә кирәк. Әле шул сыйфатларны булдырган хәлдә дә ахырын безнеңчә көтү проблемга әйләнүе бар.

### Әтине тыңлап үскән кыз бәхетле була

Аллага шөкер, бүгенге көндә мин бәхетле әтиләр исемлегендә. Моның өчен Ходай Тәгаләгә мең-мең рәхмәтлемен. Наиләне тәрбияләгәндә халкымда, динебез Исламда, нәселемдә булган яхшы сыйфатларны кызымда булдырырга көч куйдым. Социализм чорында, үзем коммунист буларак, кызымны әле сигезенче сыйныфта ук намазлыкка бастырдым. Тыңлады. Рәхмәт үзенә. Ул еллар татар милли хәрәкәтенең аякка басу еллары иде. “Туган тел” җәмгыятенең һәр утырышына минем белән йөрде. Тыңлап кына утырмады, минем белән һәр бәйрәмне сәхнәдән алып баручы да булды. 1989 елда өлкә радиосында ике тавышка “Иделкәем-илкәем” исемле радиожурналны алып бардык. Еллар узгач, бу тапшыруларны ул үзе генә алып бара торган булды. 1992 елдан 2002 елга кадәр “Ак бәхет” тапшыруларын туры эфирда алып баруны үз җилкәсенә алды.

### Үзе теккән күлмәкләрне киде

Наиләнең мәктәп елларында хезмәт дәресләре бар иде. Аларны тегәргә өйрәттеләр. Кулы тегү машинасына килешеп торды. Кияүгә чыкканчы күлмәкләрне үзе тегеп киде. Бу сыйфаты минем әнидән күчкән дип саныйм, чөнки әнием бер көтү баланы үзе тегеп үзе киендерә иде. Намазны да Наиләгә әнием өйрәтеп калдырды.

### Наилә Казан басмаларын укып үсте

Кайда гына яшәсәм дә, мин өемә Казанда чыга торган “Казан утлары”, “Идел”, “Сөембикә”, “Ялкын”, “Чаян” журналларын, “Ватаным Татарстан”, “Татарстан яшьләре”, “Сабантуй” һәм башка гәҗитәләрне яздырып алдым. Наилә шул басмаларны укып үсте. Татар телен яхшы белгәнгә, урыс теленнән дә һәрвакыт «бишле» булды. Мәктәпне медальга тәмамлады.

### Яратуыңны татар егетенә кияүгә чыгу белән кайтар

Офицер булып хезмәт иткәнгә, акчага кысылып яшәмәдем. Телләгән киемен алырга рәхсәт итә идем. Итәгемә утырып, кочаклап, рәхмәтләрен әйтә торган иде. Минем: ”Иң әлек рәхмәтне Ходай Тәгаләгә әйтә торган бул, анныры әти-әниеңә. Яратуыңны татар егетенә кияүгә чыгу белән кайтар”, диюмне тормышка ашырды, Аллага шөкер. Самар дәүләт университетын тәмамлады. Кияүгә чыкты. Ире белән ике кыз үстерәләр.

### Замана башка булса да, татарның гореф-гадәте бер!

Замана башка, мохит башка, җиһаз башка. Наилә рульдә. Балалары кампитрда йөзәләр, кулларында фото һәм кинокамера, ләкин дә йөрәкләрендәге татарлык хисләрен һәм динебез Исламга тирән мәхәббәтләрен намазлыкта куәтлиләр. Дүрт телдә сөйләшә белгәннәрен санап киткәндә татар телен беренче урынга куюлары Шамил бабаларының йөрәгенә сары май.

### Бусаганы атлап кергәч, татар теле - дәүләт теле

“Бусаганы атлап кергәч, өйдә дәүләт теле - татар теле”, дигән гаиләмдәге шигар бүген кызым Наилә өендә хөкем сөрә. Татар теле аша динебез таләпләрен һәм гореф-гадәтләрне сеңдерү - иң ышанычлы юлларның берсе. Балаларымны тәрбияләгәндә бер максат куйдым - “Сез - татар милләтен саклаучылар”. Кызым Наиләдә бу принципның тормышка ашыруын күрү миңа үзенә бер ләззәт һәм көч бирә. Бу юлның дөреслеген раслый. Самар татар милли хәрәкәтендә әтиле-кызлы 25 ел буена хезмәт итүем, куйган көчемнең юкка түгелмәгән күрү миңа даими көч өстәп тора. Шуңа да һәр татар егетен, һәр татар кызын үз балаларым кебек яратам һәм аларны да татар итеп тәрбияләүдән ләззәт алып яшим.

**Шамил БАҺАУТДИН.**

**Намаз вакытлары** — Хиҗри буенча 1434 ел — Март ае тәкъвиме — Милади буенча 2013 ел — **Время намазов**

| Көннәр саны | | Хиҗри буенча | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Зәвәл | Өйлә | Икенде | Ахшам | Көн озынлыгы | Ястү |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Җомга | 19 Рабиг | 5:57 | 7:27 | 12:52 | 13:05 | 16:23 | 18:20 | *10:53* | 19:50 |
| 2 | шимбә | 20 әл-әхир | 5:55 | 7:25 | 12:52 | 13:05 | 16:24 | 18:22 | *10:57* | 19:52 |
| 3 | якшәмбе | 21 | 5:53 | 7:23 | 12:52 | 13:05 | 16:26 | 18:24 | *11:01* | 19:54 |
| 4 | дүшәмбе | 22 | 5:53 | 7:23 | 12:52 | 13:05 | 16:26 | 18:24 | *11:01* | 19:54 |
| 5 | сишәмбе | 23 | 5:51 | 7:21 | 12:51 | 13:05 | 16:28 | 18:25 | *11:04* | 19:55 |
| 6 | чәршәмбе | 24 | 5:46 | 7:16 | 12:51 | 13:05 | 16:31 | 18:29 | *11:13* | 19:59 |
| 7 | пәнҗешәмбе | 25 | 5:44 | 7:14 | 12:51 | 13:05 | 16:33 | 18:31 | *11:17* | 20:01 |
| 8 | җомга | 26 | 5:41 | 7:11 | 12:51 | 13:05 | 16:34 | 18:33 | *11:22* | 20:03 |
| 9 | шимбә | 27 | 5:39 | 7:09 | 12:50 | 13:05 | 16:36 | 18:35 | *11:26* | 20:05 |
| 10 | якшәмбе | 28 | 5:37 | 7:07 | 12:50 | 13:05 | 16:37 | 18:37 | *11:30* | 20:07 |
| 11 | дүшәмбе | 29 | 5:37 | 7:07 | 12:50 | 13:05 | 16:37 | 18:37 | *11:30* | 20:07 |
| 12 | сишәмбе | 30 | 5:34 | 7:04 | 12:50 | 13:05 | 16:39 | 18:39 | *11:35* | 20:09 |
| 13 | чәршәмбе | Җөмәд 1 | 5:29 | 6:59 | 12:49 | 13:05 | 16:42 | 18:42 | *11:43* | 20:12 |
| 14 | пәнҗешәмбе | әл-әүвәл 2 | 5:27 | 6:57 | 12:49 | 13:05 | 16:44 | 18:44 | *11:47* | 20:14 |
| 15 | җомга | 3 | 5:25 | 6:55 | 12:49 | 13:05 | 16:45 | 18:46 | *11:51* | 20:16 |
| 16 | шимбә | 4 | 5:22 | 6:52 | 12:48 | 13:05 | 16:47 | 18:48 | *11:54* | 20:18 |
| 17 | якшәмбе | 5 | 5:20 | 6:50 | 12:48 | 13:05 | 16:48 | 18:50 | *12:00* | 20:20 |
| 18 | дүшәмбе | 6 | 5:17 | 6:47 | 12:48 | 13:05 | 16:50 | 18:51 | *12:04* | 20:21 |
| 19 | сишәмбе | 7 | 5:17 | 6:47 | 12:48 | 13:05 | 16:50 | 18:51 | *12:04* | 20:21 |
| 20 | чәршәмбе | 8 | 5:13 | 6:43 | 12:47 | 13:05 | 16:52 | 18:55 | *12:12* | 20:25 |
| 21 | пәнҗешәмбе | 9 | 5:10 | 6:40 | 12:47 | 13:05 | 16:54 | 18:57 | *12:17* | 20:27 |
| 22 | җомга | 10 | 5:08 | 6:38 | 12:47 | 13:05 | 16:55 | 18:59 | *12:21* | 20:29 |
| 23 | шимбә | 11 | 5:05 | 6:35 | 12:46 | 13:05 | 16:57 | 19:00 | *12:25* | 20:30 |
| 24 | якшәмбе | 12 | 5:03 | 6:33 | 12:46 | 13:05 | 16:58 | 19:02 | *12:29* | 20:32 |
| 25 | дүшәмбе | 13 | 5:01 | 6:31 | 12:46 | 13:05 | 17:00 | 19:04 | *12:33* | 20:34 |
| 26 | сишәмбе | 14 | 4:58 | 6:28 | 12:45 | 13:05 | 17:01 | 19:06 | *12:38* | 20:36 |
| 27 | чәршәмбе | 15 | 4:56 | 6:26 | 12:45 | 13:05 | 17:02 | 19:08 | *12:42* | 20:38 |
| 28 | пәнҗешәмбе | 16 | 4:53 | 6:23 | 12:45 | 13:05 | 17:04 | 19:10 | *12:47* | 20:40 |
| 29 | җомга | 17 | 4:51 | 6:21 | 12:44 | 13:05 | 17:05 | 19:11 | *12:50* | 20:41 |
| 30 | шимбә | 18 | 4:49 | 6:19 | 12:44 | 13:05 | 17:06 | 19:13 | *12:54* | 20:43 |
| 31 | якшәмбе | 19 | 4:46 | 6:16 | 12:44 | 13:05 | 17:08 | 19:15 | *12:59* | 20:45 |
| Дни | | Хиджри | Фаджр | Восход | Зенит | Зухр | Аср | Магриб | Долгота дня | Иша |